
б) 1 өлештә:

беренче абзацта «I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны» сүзләрен «Җитештерү һәм куллану калдыкларын» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларның» сүзләрен «җитештерү һәм куллану калдыкларының» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «I — IV классла хәвефлелектәге калдыкларны» сүзләрен «җитештерү һәм куллану калдыкларын» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «I — IV классла хәвефлелектәге калдыкларны» сүзләрен «җитештерү һәм куллану калдыкларын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Калдыкларның төренә һәм калдыкларның хәвефлелек классына карап, калдыкларны төяү-бушату эшләренә, аларны маркировкалауга, экологик иминлекне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә дифференциацияләнгән таләпләр карала торган I — IV классла хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалау тәртибе, федераль башкарма хакимиятнең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыручы органы белән килештереп, федераль башкарма хакимиятнең транспорт өлкәсендәге органы тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 12 гыйнваре
№ 1-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 2. Татарстан Республикасында парламент контроле турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

I бүлек. **Парламент контроле нигезләре**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба — Дәүләт Советы), Дәүләт Советы Президиумы, Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре, Дәүләт Советы депутатлары, парламент тикшерүен үткәрү өчен нигез булган фактларны һәм хәлләрне тикшерү буенча парламент комиссиясе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба — Хисап палатасы) тарафыннан парламент контролен гамәлгә ашыруга бәйле иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Парламент контролен гамәлгә ашыруның хокукый нигезе**

Парламент контролен гамәлгә ашыруның хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән законнары, Дәүләт Советы Регламенты тәшкил итә.

3 статья. **Парламент контроле максатлары**

Парламент контроленең төп максатлары түбәндәгеләр:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен үтәүне, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын башкаруны тәэмин итү;

2) Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау;

3) законлылык һәм хокук тәртибен ныгыту;

4) Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегендәге төп проблемаларны ачыклау, дәүләт идарәсе системасы нәтиҗәлелеген һәм парламент контролен гамәлгә ашыру барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү максатларында аларга тиешле дәүләт органнарының һәм вазыйфаи затларның игътибар итүен арттыру;

5) коррупциягә каршы көрәш;

6) Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын куллану тәҗрибәсен өйрәнү, Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү, шулай ук аларны башкару нәтиҗәлелеген арттыру.

4 статья. **Парламент контроле принциплары**

Парламент контроле түбәндәге принципларда гамәлгә ашырыла:

1) законлылык;

2) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү;

3) дәүләт хакимиятенең закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренә

бүленүе;

4) парламент контроле субъектларының мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге;

5) системалылык;

6) хәбәрдарлык.

5 статья. **Парламент контроле турында мәгълүматның ачык булуы**

Дәүләт Советы, федераль законнар нигезендә файдалану мөмкинлеге чикле булган мәгълүматтан тыш, җәмгыять һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, парламент контроле турындагы мәгълүматтан һәркемнең файдалана алуын тәэмин итә.

6 статья. **Парламент контролен гамәлгә ашыру чикләре**

Парламент контролен гамәлгә ашыру суд эшчәнлеген башкаруны, җинаятьләр тикшерүне, оператив-эзләү эшчәнлеген, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә гамәлгә ашыра торган эшчәнлеген



алмаштырмый. Парламент контроле субъектларының күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруга тыкшынуы рөхсәт ителми.

7 статья. **Парламент контроле субъектлары**

1. Парламент контроле субъектларына парламент контролен гамәлгә ашыру максатларында эшләүче түбәндәгеләр керә:

1) Дәүләт Советы;

2) Дәүләт Советы Президиумы;

3) Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре;

4) парламент тикшерүен үткәрү өчен нигез булган фактларны һәм хәлләрне тикшерү буенча парламент комиссиясе;

5) Дәүләт Советы депутатлары.

2. Хисап палатасы парламент контролен гамәлгә ашыруда әлеге Законда һәм «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законы) каралган очракларда, тәртиптә һәм рәвешләрдә катнаша.

8 статья. **Парламент контроле рәвешләре**

Дәүләт Советы карамагына кертелгән вәкаләтләр кысаларында парламент контролен гамәлгә ашыру эшчәнлегенә түбәндәгеләр керә:

1) Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Премьер-министрына һәм аның урынбасарларына ышанычсызлык белдерү турындагы мәсьәләне карау;

2) Дәүләт Советы, Дәүләт Советы комитетлары тарафыннан бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә башлангыч, агымдагы һәм алга таба парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын үткәрү;

3) Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча еллык хисапларны тыңлау;

4) Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының полиция эшчәнлеге турындагы еллык хисапларын тыңлау;

5) Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республика-

сы Законында билгеләнгән тәртиптә Дәүләт Советы депутатлары гарызнамәләрен, тәкъдимнәр, депутат мөрәҗәгатьләрен җибәрү;

6) Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба — Министрлар Кабинеты) әгъзалары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары мәгълүматын, «хөкүмәт сәгате» кысаларында Дәүләт Советы депутатларының сорауларына күрсәтелгән вазыйфаи затларның җавапларын тыңлау, шулай ук Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышларында күрсәтелгән вазыйфаи затларның мәгълүматын тыңлау;

7) Дәүләт Советының Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

8) Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда һәм рәвешләрдә Хисап палатасы белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

9) Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда һәм рәвешләрдә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

10) Министрлар Кабинеты әгъзаларын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затларын Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышларына чакыру;

11) парламент тыңлауларын уздыру;

12) парламент тикшерүләрен үткәрү.

### 9 статья. Әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актлар чыгарганда парламент контроле

1. Дәүләт Советы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны кабул итүнең билгеләнгән срокларының Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан үтәлешен тәэмин итүне, шулай ук тиешле кимчелекләрне ачыклау максатларында тиешле хокук мөнәсәбәтләрен җайга салуның тулылыгын тикшереп тора.



2. Министрлар Кабинеты квартал тәмамланган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча Дәүләт Советына әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны әзерләү барышы һәм аларны кабул итүнең күз алдында тотылган сроклары турында мәгълүмат җибәрә.

## II бүлек. Парламент контроленең аерым рәвешләре

### 10 статья. Дәүләт Советы депутатлары сорауларына Министрлар Кабинеты әгъзаларының һәм башка вазыйфаи затларның җавапларын тыңлау

1. Дәүләт Советы Министрлар Кабинеты әгъзаларын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затларын Дәүләт Советы утырышларына Дәүләт Советы депутатлары сорауларына җавапларны тыңлау өчен чакырырга хокуклы.

2. Дәүләт Советы утырышларында Дәүләт Советы депутатлары сорауларына Министрлар Кабинеты әгъзаларының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затларының җаваплары өчен вакыт («хөкүмәт сәгате») бирелергә мөмкин. Дәүләт Советы утырышына «хөкүмәт сәгате» кысаларында Министрлар Кабинеты әгъзалары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затлары белән бергә Хисап палатасы эшчәнлегенең тиешле юнәлешен җитәкләүче Хисап палатасы аудиторы чакырылырга мөмкин.

3. «Хөкүмәт сәгате»н үткәрү барышында тиешле юнәлешләрдә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге мәсьәләләре, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән расланган максатчан күрсәткечләргә ирешү мәсьәләләре буенча фикер алышу булырга мөмкин.

4. Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре үз утырышларына министрларны һәм алар вәкаләт биргән вазыйфаи затларны чакырырга хокуклы.

### 11 статья. Парламент тикшерүе

1. Парламент тикшерүе түбәндәгеләргә карата үткәрелергә тиеш:

1) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән кеше һәм граждан

хокукларын һәм ирекләрен тупас яисә массакүләм бозу фактларына;

2) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга бәйле хәлләргә;

3) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән килгән зыяннарга бәйле хәлләргә;

4) Татарстан Республикасы бюджетының керем һәм (яисә) чыгым статьяларын күләм, структура һәм максатчан билгеләнеш буенча үз вакытында үтәмәүдә, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту, Татарстан Республикасы дәүләт милкенә идарә итү һәм аның белән эш итү нәтиҗәсезлегендә чагылган финанс дисциплинасын тупас бозу фактларына.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактлар һәм хәлләр булганда, саны Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынnan кимендә өчтән берен тәшкил иткән депутатлар төркеме таләбе буенча Дәүләт Советы Президиумы, Дәүләт Советы комитеты (комитетлары) карары белән Дәүләт Советы парламент тикшерүе билгеләргә мөмкин.

3. Парламент тикшерүе Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә. Парламент тикшерүен билгеләү турындагы мәсьәлә Дәүләт Советы утырышына Дәүләт Советы карары проекты рәвешендә кертелә, анда парламент тикшерүе үткәрелергә тиешле фактлар һәм хәлләр күрсәтелә, парламент тикшерүен уздыру өчен парламент комиссиясе (алга таба — парламент комиссиясе) составы һәм парламент комиссиясе хакындагы нигезләмә билгеләнә.

4. Парламент комиссиясе Дәүләт Советы депутатлары санынnan парламент тикшерүен үткәрү вакытына комиссия рәисе, аның урынбасары, комиссия әгъзалары составында оештырыла.

5. Парламент комиссиясе утырышын комиссия рәисе, ә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары уздыра. Парламент комиссиясе утырышында комиссия әгъзаларының гомуми санынnan яртысыннан артыграгы катнашса, ул тулы хокуклы була. Парламент комиссиясе карары утырышта катнашучы комиссия әгъзалары санынnan күпчелек тавыш белән кабул ителә.

6. Парламент комиссиясе эшен Дәүләт Советы Аппараты тәэмин итә. Парламент комиссиясенең һәр утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары парламент тикшерүен үткәрүдә кирәкле ярдәм күрсәтәләр, мәгълүмат бирү турындагы федераль законнар нигезендә парламент комиссиясе эше өчен кирәкле белешмәләрне һәм документларны тоткарлыксыз тапшыралар.

8. Парламент комиссиясе үз эшенә экспертлар җәлеп итәргә хокуклы.

9. Эш нәтиҗәләре буенча парламент комиссиясе нигезләнгән бәяләмә әзерли, анда парламент комиссиясе тикшерә торган фактлар һәм хәлләр буенча аның нәтиҗәләре булырга тиеш. Бәяләмәгә комиссия рәисе имза сала.

10. Бәяләмәне раслау турында мәсьәлә Дәүләт Советы утырышына Дәүләт Советы карары проекты рәвешендә кертелә. Бәяләмәне Дәүләт Советының сайланган депутатлары санынnan яртысыннан артыграгы хупласа, ул расланган булып санала.

11. Парламент комиссиясе бәяләмәсен раслау турындагы Дәүләт Советы карары парламент комиссиясе бәяләмәсе белән бергә дәүләт органына, җирле үзидарә органына, оешмага, тиешле вазыйфаи затларга әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактларны һәм хәлләрне бетерү, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү чараларын күрү өчен җибәрелә.

12 статья. **Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә Дәүләт Советы тарафыннан парламент контролен гамәлгә ашыру**

1. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге парламент контроленә башлангыч, агымдагы һәм алга таба гамәлгә ашырыла торган парламент контроле керә.

2. Башлангыч парламент контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәгеләр башкарыла:

1) Татарстан Республикасының бюджет, салым сәясәтенең төп юнәлешләре проектлары һәм озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы проекты (бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) буенча фикер алышу;

2) Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне карау;

3) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы проекты һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы проекты буенча фикер алышуда катнашу;

4) Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республи-

касы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы проектын һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы проектын карау һәм раслау.

3. Агымдагы парламент контроле кысаларында Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышларында, парламент тыңлаулары барышында, депутат гарызнамәләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре карала.

4. Алга таба гамәлгә ашырыла торган парламент контроле кысаларында Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисаплар карала һәм раслана. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше хакындагы еллык хисапны караганда Дәүләт Советы Татарстан Республикасы финанс министрының Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы докладын һәм Хисап палатасы Рәисенең Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше хакындагы еллык хисапка Хисап палатасы бәяләмәсе турындагы докладын тыңлый.

5. Хисап палатасы бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә парламент контролен гамәлгә ашыруда катнашуга «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәлеп ителә.

## III бүлек. Парламент контролен планлаштыру һәм гамәлгә ашыру

### 13 статья. Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын планлаштыру

1. Парламент контролен гамәлгә ашыру чаралары даими һәм бер тапкыр булырга мөмкин.

2. Парламент контролен гамәлгә ашыру чаралары Дәүләт Советы Президиумы, депутат берләшмәләре, Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре, Дәүләт Советы депутатлары тәкъдимнәре белән Дәүләт Советы чаралары планына кертелергә мөмкин.

3. Дәүләт Советы тарафыннан Хисап палатасы катнашында үткәрелә торган даими парламент контролен гамәлгә ашыру чаралары Хисап палатасының чираттагы елгы эш планына кертелә



һәм «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

### 14 статья. Парламент контролен оештыру, хокукый, методик һәм аналитик тәэмин итү

1. Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын оештыруда һәм үткәрүдә гомуми җитәкчелекне Дәүләт Советы Рәисе һәм аның урынбасарлары гамәлгә ашыра.

2. Парламент контролен оештыру, хокукый, методик һәм аналитик тәэмин итүне Дәүләт Советы Аппараты башкара.

### 15 статья. Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карарлары

1. Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасының тиешле закон проектын аны закон чыгару инициативасы тәртибендә Дәүләт Советына кертү өчен эшләүне Дәүләт Советы комитетына (комитетларына) йөкләргә, шулай ук Министрлар Кабинетына тәкъдим итәргә;

2) дәүләт органына, җирле үзидарә органына, оешмага, тиешле вазыйфаи затларга ачыкланган закон бозуларны бетерү, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү чараларын күрергә тәкъдим итәргә;

3) Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Премьер-министрына һәм аның урынбасарларына ышанычсызлык белдерү турындагы мәсьәләне карарга;

4) үз вазыйфасына билгеләп куюю һәм вазыйфасыннан азат итү Дәүләт Советы карамагында булган затларны законнар белән билгеләнгән тәртиптә вазыйфадан азат итәргә;

5) Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә эшчәнлеге канәгатьләнерлек булмаган затларны вазыйфадан азат итү турындагы карарлар кабул итәргә хокуклы затларга мөрәҗәгать итәргә;

6) хокук саклау органнарына, дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнарына мөрәҗәгать итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә аларның тиешле вазыйфаи затлары парламент контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы

тәкъдимнәрен карарга һәм бер ай эчендә яисә Дәүләт Советы билгеләгән вакытта тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында Дәүләт Советына хәбәр итәргә тиеш. Федераль дәүләт хакимияте органнары һәм аларның вазыйфаи затлары парламент контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы тәкъдимнәрен карауны федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашыра.

16 статья. **Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 142 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2);

2) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 29 июнендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 14 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 6 (I өлеш).

17 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 12 гыйнвары
№ 2-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 3. Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон авыл халкының эш белән тәэмин ителешен арттыру һәм матди хәлен яхшырту, Татарстан Республикасының азык-төлек базарын үстерүгә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Шәхси ярдәмче хуҗалык граждан яисә граждан һәм аның белән бергә яшәүче һәм (яисә) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны гамәлгә ашыручы гаилә әгъзалары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яисә) сатып алынган җир кишәрлегендә шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында алып барыла.

2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып барганда җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясе шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның милке булып тора.

3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалык алып барганда җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен реализацияләве эшкуарлык эшчәнлеге булып тормый.

4. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен торак пункт чикләрендәге җир кишәрлеге (өй янындагы җир кишәрлеге) һәм торак пункт чикләреннән читтәге җир кишәрлеге (кырдагы җир кишәрлеге) файдаланылырга мөмкин.

5. Өй янындагы җир кишәрлеге авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен, шулай ук, шәһәр төзелеше, төзелеш, экология, санитария-гигиена, янгынга каршы һәм башка кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәгән килеш, торак йорт, җитештерү,

көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар, төзелмәләр торгызу өчен файдаланыла.

6. Кырдагы җир кишәрлеге анда биналар һәм корылмалар торгызу хокукыннан башка бары тик авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен генә файдаланыла.

**3 статья. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен закон чыгарып җайга салу;

2) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменә юнәлдерелә торган акчалар күләмен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары составында раслау;

3) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**4 статья. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органын билгеләү;

3) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

4) Татарстан Республикасы бюджетының шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменә юнәлдерелә торган акчалар күләмен билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.



**5 статья. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) әлеге Законда каралган рәвешләрдә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә финанс ярдәме системасы эшләвен тәэмин итү;

2) шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, әзерләү, эшкәртү һәм реализацияләү чаралары белән тәэмин итүгә бәйле оештыру механизмнарын камилләштерү;

3) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**6 статья. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру чаралары**

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру чараларына түбәндәгеләр керергә мөмкин:

1) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга терлек азыклары; товар өчен һәм нәселле сыерлар, таналар, кәҗәләр, авыл хуҗалыгы өчен яшь терлекләр, кош-корт (казлар, үрдәкләр, күркәләр, бройлер чебешләр) бәбкәләре; терлекчелек һәм кошчылык өчен технологик җайланмалар; сакланган туфракта яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен орлык һәм утырту материалы, материаллар һәм җайланмалар сатып алуда; мәгълүмати-консультатив хезмәт күрсәтүләрдә ярдәм итү;

2) авыл хуҗалыгы хайваннарына ветеринария хезмәте күрсәтүне оештыру, авыл хуҗалыгы хайваннары һәм кошлары авыруларына каршы көрәш;

3) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативлары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары төзүдә ярдәм итү;

4) шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу эшләрен оештыру;

5) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү өчен кредит ресурслары җәлеп итүдә ярдәм итү;

6) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка чаралар.

7 статья. **Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең финанс чаралары**

1. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең финанс чараларына түбәндәгеләр керергә мөмкин:

1) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга бәйле максатларда алынган озак сроклы, уртача һәм кыска сроклы кредитлар буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр;

2) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга түбәндәгеләргә бирелгән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр:

а) сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзүгә;

б) товар өчен һәм нәселле таналар һәм бер бозаулаган сыерлар сатып алуга;

в) товар өчен һәм нәселле кәҗәләр сатып алуга;

г) кош-корт (казлар, үрдәкләр, күркәләр, бройлер чебешләр) бәбкәләре сатып алуга;

д) сыерларны ясалма орлыкландыру буенча хезмәт күрсәтүләргә;

е) өч яшьтән зуррак бияләр асрау өчен азыклар сатып алуга;

ж) сыерлар асрауда хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүгә;

з) сакланган туфракта яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен элита сортлы орлык һәм утырту материалы, материаллар һәм җайланмалар сатып алуга;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка чаралар.

2. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең конкрет финанс чаралары авыл хуҗалыгына дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программасы белән билгеләнә.

8 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 12 гыйнваре
№ 3-ТРЗ





## 4. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9), аңа түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«17) исәпкә куелуыннан башлап 10 ел дәвамында оешма балансында исәптә торган мөлкәткә карата Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территория резидентлары булган оешмалар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 13 феврале
№ 4-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 5. Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

1. Социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның салым ставкасын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

5 процент – социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым исәбе мәгълүматлары буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап биш салым чоры дәвамында;

10 процент – социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым исәбе мәгълүматлары буенча беренче табыш алынган салым чорыннан санала торган алтынчы салым чорыннан башлап унынчы салым чоры тәмамланганчы.

2. Әгәр резидент социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән ул резидентлар реестрына кертелгән салым чорыннан башлап өч салым чоры дәвамында табыш алмаган булса, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган сроклар мондый салым түләүче өчен ул резидентлар



реестрына кертелгән салым чорыннан санала торган дүртенче салым чорыннан исәпләнә башлый.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган (эшчәнлеккә бәйле тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) һәм башка эшчәнлек башкарганда алынган (тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) исәбе резидентлар тарафыннан һәркайсы аерым алып барылганда гына кулланыла.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 13 феврале
№ 5-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 6. «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма Басмасы, 2015, № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре буенча Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару кысаларында дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү (хезмәтләр күрсәтү) чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0059 0 | | 193 319,1 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0059 0 | 100 | 126 902,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0059 0 | 200 | 63 708,4 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0059 0 | 800 | 2 708,0» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 193 319,1 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | 100 | 126 902,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | 200 | 63 708,4 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | 800 | 2 708,0». |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 16 феврале
№ 6-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 7. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларында катнашучылар составына җирле үзидарә органнарының законнар белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи затлары, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре кертелә, шулай ук гражданнар, территориаль иҗтимагый җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр вәкилләре кертелергә мөмкин.»;

2) 2 өлештә «законнар белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтләр бирелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елнын 18 феврале
№ 7-ТРЗ

## 8. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш), 5 пунктка «, халыкның азмобильле төркемнәре өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында подъездларга керү урыннарын пандуслар белән һәм баскычларны ике яктан култыксалар белән җиһазлау» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елнын 22 феврале
№ 8-ТРЗ





## 9. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $2^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктында «Җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү. Җәмәгать туклануы предприятиеләре классификациясе» ГОСТ Р 50762-2007» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $2^1$ статьяда «Аз алкогольле тонусны күтәрә торган эчемлекләр. Гомуми техник шартлар» ГОСТ Р 52845-2007» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елнын 22 феврале
№ 9-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 10. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе секретариаты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе секретариатын түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Секретариат җитәкчесе:

Ганиев Илшат Газим улы

Секретариат әгъзалары:

Габделхаков Рөстәм Рифгать улы
Владимирова Ксения Андреевна
Комисаров Александр Владимирович
Славутский Александр Яковлевич.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 феврале
№ 1045-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 11. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе регламент төркеме турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе регламент төркемен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Төркем җитәкчесе:

Галиев Марат Һади улы

Төркем әгъзалары:

Хөснетдинов Мөхәммәтвәли Гомәр улы
Шамилов Илдар Әсхәт улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 феврале
№ 1046-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 12. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Комиссия җитәкчесе:

Сәлахов Мәгъсүм Хәлимулла улы

Комиссия әгъзалары:

Сөләйманов Рәис Әхтәм улы
Шәһитов Марат Фоат улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 феврале
№ 1047-V ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 13. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе редакция комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның язгы сессиясе редакция комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Редакция комиссиясе җитәкчесе:

Рәхмәтуллин Рауил Шәйдәүләт улы

Редакция комиссиясе әгъзалары:

Вәлиев Фоат Вәли улы
Зубарев Вячеслав Викторович
Сыровацкий Михаил Федорович
Хәлимов Рөстәм Хәмис улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 феврале
№ 1048-V ДС



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 14. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча 4 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. 2015 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының хисабы.
4. «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 194-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 196-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 197-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 183-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 189-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр

кертү хакында» 190-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 195-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 199-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 177-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $2^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 193-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 178-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.

19. «2015 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.

20. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым



закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 990393-6 номерлы федераль закон проектын кире кагу һәм «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 951450-6 номерлы федераль закон проектын карауны тизләтү тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга мөрәҗәгать итүе турында.

21. «Капиталь төзелеш объектларын техник исәпкә алу нигезләре турында» 943920-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

22. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 961811-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметын төгәлләштерү һәм төзелешне тикшереп тору кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

23. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 945963-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану ноктасы булмаган торак пунктлар исемлеген Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләмичә, мондый торак пунктлар исемлеген раслау вәкаләтләрен бирү өлешендә).

24. «Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү турында» 949621-6 номерлы федераль закон проекты хакында (урманнардан юл сервисы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалануны хокукый җайга салу өлешендә).

25. «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^2$ һәм $39^{21}$ статьяларына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның $3^3$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 961795-6 номерлы федераль закон проекты турында (җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән

җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләрен үзгәртү өлешендә).

26. «Махсус саклanылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының — Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

27. «Махсус саклanылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мурманск өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

28. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына инвалидларга күпфатирлы йортлардагы торак урынына каршылыксыз кереп йөрү өчен шартлар тәэмин итү мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында» 943020-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

29. «Россия Федерациясендә туберкулез таралуны кисәтү турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 943028-6 номерлы федераль закон проекты турында (туберкулезга бәйле рәвештә диспансер күзәтүендә булган затларның һәм туберкулез белән авыручыларның бурычлары хакында).

30. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына тәмәке продукциясен ваклап сату һәм куллану рөхсәт ителгән яшьне арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 947033-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 923016-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ кулга алу срокларын төгәлләштерү өлешендә).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексын гамәлгә кертү хакында» Федераль законга үзгәреш кертү турында» 929664-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 29.4 һәм 29.6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 943074-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү хакында).



34. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә йөрү ирегенә, булу һәм яшәү урыны сайлауга хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 946596-6 номерлы федераль закон проекты турында (махсуслаштырылган торак фондына кертелгән торак урыннары төрләренең тулы булмаган исемлеген төшереп калдыру максатларында).

35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.5 статьясында каралган хокук бозулар буенча җаваплылыкны көчәйтү, алар буенча хөкем ителү срогын арттыру һәм административ тикшерүне булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 950775-6 номерлы федераль закон проекты турында.

36. «Хәрби хезмәткәрләрне торак белән тәэмин итүнең тупланма-ипотека системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 952652-6 номерлы федераль закон проекты турында (тупланма-ипотека системасы эшләве өлешендә аерым нигезләмәләрне төгәлләштерү хакында).

37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 953373-6 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә хокук бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

### 64. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турнында» 950392-6 номерлы федераль закон проекты хакында (экологик экспертиза өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турнында» 950392-6 номерлы федераль закон проектын (экологик экспертиза өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 феврале
№ 1099-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 65. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында (чит ил пассажир ташучыларына, транспорт чаралары милекчеләренә (хуҗаларына) караган транспорт чаралары хәрәкәтен махсус җайланмалар кулланып туктату юлы белән тоткарлау очракларын ачыклау турында)» 965924-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында (чит ил пассажир ташучыларына, транспорт чаралары милекчеләренә (хуҗаларына) караган транспорт чаралары хәрәкәтен махсус җайланмалар кулланып туктату юлы белән тоткарлау очракларын ачыклау турында)» 965924-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 феврале
№ 1100-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 66. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышын 2016 елның 11 февралендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 4 феврале
№ 1037-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 67. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча 4 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. 2015 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының хисабы.

4. «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 194-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 196-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

6. «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 197-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 183-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 189-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 190-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 177-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урынына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $2^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 193-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 178-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).



15. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.

17. «2015 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.

18. «Капиталь төзелеш объектларын техник исәпкә алу нигезләре турында» 943920-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

19. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 961811-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметын төгәлләштерү һәм төзелешне тикшереп тору кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

20. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 945963-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану ноктасы булмаган торак пунктлар исемлеген Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләмичә, мондый торак пунктлар исемлеген раслау вәкаләтләрен бирү өлешендә).

21. «Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү турында» 949621-6 номерлы федераль закон проекты хакында (урманнардан юл сервисы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалануны хокукый җайга салу өлешендә).

22. «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{2}$ һәм $39^{21}$ статьяларына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның $3^{3}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 961795-6 номерлы федераль закон проекты турында (җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләрен үзгәртү өлешендә).

23. «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

24. «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мурманск өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

25. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына инвалидларга күпфатирлы йортлардагы торак урынына каршылыксыз кереп йөрү өчен шартлар тәэмин итү мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында» 943020-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

26. «Россия Федерациясендә туберкулез таралуны кисәтү турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 943028-6 номерлы федераль закон проекты турында (туберкулезга бәйле рәвештә диспансер күзәтүендә булган затларның һәм туберкулез белән авыручыларның бурычлары хакында).

27. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына тәмәке продукциясен ваклап сату һәм куллану рөхсәт ителгән яшьне арттыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 947033-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 923016-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ кулга алу срокларын төгәлләштерү өлешендә).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексын гамәлгә кертү хакында» Федераль законга үзгәреш кертү турында» 929664-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 29.4 һәм 29.6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 943074-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү хакында).

31. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә йөрү ирегенә, булу һәм яшәү урыны сайлауга хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 946596-6 номерлы федераль закон проекты турында (махсуслаштырылган торак фондына кертелгән торак урыннары төрләренең тулы булмаган исемлеген төшереп калдыру максатларында).



32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.5 статьясында каралган хокук бозулар буенча җаваплылыкны көчәйтү, алар буенча хөкем ителү срогын арттыру һәм административ тикшерүне булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 950775-6 номерлы федераль закон проекты турында.

33. «Хәрби хезмәткәрләрне торак белән тәэмин итүнең тупланма-ипотека системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 952652-6 номерлы федераль закон проекты турында (тупланма-ипотека системасы эшләве өлешендә аерым нигезләмәләрне төгәлләштерү хакында).

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 953373-6 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә хокук бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 954365-6 номерлы федераль закон проекты турында (полиция хезмәткәрләренә 6.91 статья буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләре бирү хакында).

36. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына хайваннарга карата рәхимсезлек кылган өчен административ җаваплылык кертү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 954756-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законның $109^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 958229-6 номерлы федераль закон проекты турында (мәҗбүри эшләрне үтәтү турындагы башкару документларын үтәүне камилләштерү өлешендә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 4 феврале
№ 1038-V ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 68. 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 4 феврале
№ 1040-V ДС

2016 елның 4 февралендәге
1040-V ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

### 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның ЯКЫНЧА ПЛАНЫ

| № | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларын әзерләү һәм уздыру** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы |
| 2. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышлары (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру мәсьәләләре буенча)** | 2 айга кимендә бер мәртәбә | Л.Н. Маврина |
| 3. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының күчмә утырышлары** | ел дәвамында | Л.Н. Маврина |
| 4. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәләре эше** | | |
| | Фракцияләр, «Бердәм Россия» фракциясе президиумы, РФКП фракциясе советы, «Татарстан – Яңа гасыр» депутат группасы утырышлары, башка чаралар, акцияләр (депутат берләшмәләренең планнары буенча) | ел дәвамында | Ю.З. Камалтынов Х.Г. Миргалимов Р.З. Закиров |
| 5. | **Парламент тыңлаулары:** | | |
| | – «2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | октябрь | Л.А. Якунин |
| 6. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары утырышлары** | кирәк булганда, әмма айга кимендә бер мәртәбә | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләре |
| | **Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты** | | |
| | 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | А.Г. Хәбибуллин |
| | Контроль мәсьәләләр: | | |
| | – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 85 статьясындагы 3 өлешен гамәлгә ашыру барышы хакында | февраль | А.Г. Хәбибуллин |
| | – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисабы хакында | март | А.Г. Хәбибуллин |
| | – «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасында муниципаль норматив хокукый актлар регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында | апрель | А.Г. Хәбибуллин |

| | | |
|---|---|---|
| – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын территориаль иҗтимагый җирле үзидарәне (ТИҖҮ) үстерү өлешендә гамәлгә ашыру буенча Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакында | май | А.Г. Хәбибуллин |
| – 2016 елда Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыруны законнар белән тәэмин итү турында | июнь | А.Г. Хәбибуллин |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әгъзалары тарафыннан «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының үзләренең сайлау округындагы эше турында мәгълүмат бирү тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәүнең барышы турында | июль | А.Г. Хәбибуллин |
| – Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлар кабул итү өлешендәге эше турында | октябрь | А.Г. Хәбибуллин |
| – Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү өлешендәге эшчәнлеге турында | ноябрь | А.Г. Хәбибуллин |
| – «2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектларының парламентлары, башка илләрнең һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлек планы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын гамәлгә ашыру барышы хакында | декабрь | А.Г. Хәбибуллин |
| Башка мәсьәләләрне карау: | | |
| – федераль закон проектлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару инициативалары һәм мөрәҗәгатьләре турында | ел дәвамында | А.Г. Хәбибуллин |



| | | |
|---|---|---|
| – чираттагы чорга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының эш планы турында | квартал саен | А.Г. Хәбибуллин |
| – «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | I квартал | А.Г. Хәбибуллин |
| – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | I квартал | А.Г. Хәбибуллин |
| – Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында («Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү өлешендә) | I квартал | А.Г. Хәбибуллин |
| – «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында | I квартал | А.Г. Хәбибуллин |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эше йомгаклары турында | декабрь | А.Г. Хәбибуллин |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшенең якынча планы турында | декабрь | А.Г. Хәбибуллин |
| – 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка илләр, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлекнең якынча планы проекты турында | декабрь | А.Г. Хәбибуллин |

**Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты**

| | | |
|---|---|---|
| 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | Ш.Ш. Яһудин |

Контроль мәсьәләләр:

| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү турында» 2011 елның 20 маендагы 53 номерлы һәм 2015 елның 10 февралендәге 90 номерлы карарларын үтәүнең барышы хакында | февраль | Ш.Ш. Яһудин |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының «Янгын куркынычсызлыгы турында» һәм «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру барышы хакында» 2015 елның 7 апрелендәге 131 номерлы карарын гамәлгә ашыру барышы турында | март | Ш.Ш. Яһудин |
| – «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары турында» һәм «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру барышы хакында («Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының күчмә утырышында) | апрель | Ш.Ш. Яһудин |
| – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында | май | Ш.Ш. Яһудин |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының «Лаеш муниципаль районында хокук тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру барышы хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге 243 номерлы карарын гамәлгә ашыру барышы турында | июнь | Ш.Ш. Яһудин |



| | | |
|---|---|---|
| – Аксубай һәм Минзәлә муниципаль районнарында «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү хакында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы турында | октябрь | Ш.Ш. Яһудин |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына караган мәсьәләләр буенча Югары Ослан һәм Чистай муниципаль районнарында җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру барышы турында» 2015 елның 11 декабрендәге 265 номерлы карарын гамәлгә ашыру барышы турында | ноябрь | Ш.Ш. Яһудин |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында» 2015 елның 2 июнендәге карарын гамәлгә ашыру барышы турында | декабрь | Ш.Ш. Яһудин |

Башка мәсьәләләрне карау:

| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларына кандидатуралар турында | ел дәвамында | Ш.Ш. Яһудин |
| – федераль закон проектлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару инициативалары һәм мөрәҗәгатьләре турында | ел дәвамында | Ш.Ш. Яһудин |
| – чираттагы чорга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты эш планы турында | квартал саен | Ш.Ш. Яһудин |

| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы каршындагы квалификация коллегиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре вазыйфаларына кандидатуралар карау турында | ноябрь | Ш.Ш. Яһудин |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты эше йомгаклары турында | декабрь | Ш.Ш. Яһудин |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты эшенең якынча планы турында | декабрь | Ш.Ш. Яһудин |

**Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты**

| | | |
|---|---|---|
| 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | Л.А. Якунин |

Контроль мәсьәләләр:

| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмәләре турында (2012 – 2014 елларда һәм 2015 елның узган чорында Татарстан Республикасы торак пунктларын су белән тәэмин итү системаларын капиталь ремонтлауга, реконструкцияләүгә, төзүгә бүлеп бирелгән дәүләт акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелегенең аудиты турында һәм 2012 – 2014 елларда һәм 2015 елның узган чорында ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелегенең аудиты турында) | I квартал | Л.А. Якунин |
| – 2016 елның I кварталында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында<br>– 2016 елның I кварталында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында | май | Л.А. Якунин |
| – 2016 елның I яртыеллыгында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында<br>– 2016 елның I яртыеллыгында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында | сентябрь | Л.А. Якунин |



| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмәсе турында | III квартал | Л.А. Якунин |
| – 2016 елның 9 аенда Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында<br>– 2016 елның 9 аенда Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында | ноябрь | Л.А. Якунин |

Башка мәсьәләләрне карау:

| | | |
|---|---|---|
| – федераль закон проектлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару инициативалары һәм мөрәҗәгатьләре турында | ел дәвамында | Л.А. Якунин |
| – чираттагы чорга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты эш планы турында | квартал саен | Л.А. Якунин |
| – 2015 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап | февраль | Л.А. Якунин |
| – «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында | июнь | Л.А. Якунин |
| – «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында | II квартал | Л.А. Якунин |
| – күчемсез мөлкәт объектларына салым салу турындагы һәм күчемсез мөлкәт объектларын кадастр исәбенә алу проблемалары турындагы законнарны гамәлгә ашыру | III квартал | Л.А. Якунин |

| | | |
|---|---|---|
| – махсус икътисадый зоналарда салым ташламалары бирүнең нәтиҗәлелеге турында | III квартал | Л.А. Якунин |
| – «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | октябрь | Л.А. Якунин |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты эше йомгаклары турында | декабрь | Л.А. Якунин |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты эшенең якынча планы турында | декабрь | Л.А. Якунин |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмәсе турында | IV квартал | Л.А. Якунин |

**Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты**

| | | |
|---|---|---|
| 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | Р.Т. Борһанов |

Контроль мәсьәләләр:

| | | |
|---|---|---|
| – ТКХ өлкәсендә энергия нәтиҗәлелеге (Казан дәүләт энергетика университетында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында) | март | Р.Т. Борһанов |



| | | |
|---|---|---|
| – Авыл хуҗалыгы техникасын машиналар җитештерүне импортка алмашу максатларында 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру турында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының уртак утырышында) | I квартал | Р.Т. Борһанов |
| – Үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрне үстерү проблемалары һәм перспективалары (Чаллы шәһәре) | апрель | Р.Т. Борһанов |
| – Татарстан Республикасында туризмны үстерү проблемалары һәм перспективалары | май | Р.Т. Борһанов |
| – Республикада торак программаларын гамәлгә ашыру проблемалары һәм перспективалары (эконом класслы, азкатлы, арендалы торак, өлешләп төзү һ.б. ) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында) | июнь | Р.Т. Борһанов |
| – Республикада гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программаларын гамәлгә ашыру йомгаклары һәм проблемалары (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында) | сентябрь | Р.Т. Борһанов |

| | | |
|---|---|---|
| – «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын мониторинглау нәтиҗәләре хакында | октябрь | Р.Т. Борһанов |
| – Россия почтасын реформалаштыруның (хосусыйлаштыруның) кайбер аспектлары турында | ноябрь | Р.Т. Борһанов |
| – Күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алуны һәм күчемсез мөлкәткә хокукны дәүләт теркәвенә алуны камилләштерү (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында) | декабрь | Р.Т. Борһанов |
| Башка мәсьәләләрне карау: | | |
| – федераль закон проектлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару инициативалары һәм мөрәҗәгатьләре турында | ел дәвамында | Р.Т. Борһанов |
| – чираттагы чорга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эш планы турында | квартал саен | Р.Т. Борһанов |
| – «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | февраль | Р.Т. Борһанов |
| – «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында | февраль | Р.Т. Борһанов |



| | | |
|---|---|---|
| – «Региональ әһәмияттәге махсус икътисадый зоналар турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | I квартал | Р.Т. Борһанов |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эше йомгаклары турында | декабрь | Р.Т. Борһанов |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эшенең якынча планы турында | декабрь | Р.Т. Борһанов |
| **Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты** | | |
| 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | Т.Г. Һадиев |
| Контроль мәсьәләләр: | | |
| – Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары мәгълүматларын карау (экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте мәсьәләләре буенча) | ел дәвамында | Т.Г. Һадиев |
| – Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының үтәлеше хакында | квартал саен | Т.Г. Һадиев |
| – күпбалалы гаиләләргә бирелә торган җир участокларын инфраструктура белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында | март | Т.Г. Һадиев |
| – 2015 елда «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Дәүләт программасын үтәү йомгаклары һәм 2016 елның I кварталына планнар турында | I квартал | Т.Г. Һадиев |

| | | |
|---|---|---|
| – Авыл хуҗалыгы техникасы һәм машиналары җитештерүне импортка алмашу максатларында 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру турында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының уртак утырышында) | I квартал | Т.Г. Һадиев |
| – Татарстан Республикасында урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу өлешендә законнарны үтәү, шулай ук әлеге максатларга юнәлдерелгән бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану турында | апрель | Т.Г. Һадиев |
| – Авыл хуҗалыгы өлкәсендә кадрларның квалификациясен күтәрү һәм аларны эшкә урнаштыру чаралары турында | май | Т.Г. Һадиев |
| – Заманча геосәяси системада тотрыклылык нигезе буларак, Җир Хартиясе | май | Т.Г. Һадиев |
| – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары сусаклагыч зоналарының һәм яр буе саклау полосаларының экологик торышы турында | июнь | Т.Г. Һадиев |
| – «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының үтәлеше хакында | сентябрь | Т.Г. Һадиев |
| – Казан шәһәре мисалында халык эчә торган суның сыйфаты һәм чистарту корылмалары торышы турында | сентябрь | Т.Г. Һадиев |
| – туфракны саклау һәм җирләрдән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә законнарның үтәлеше турында | октябрь | Т.Г. Һадиев |



| | | |
|---|---|---|
| – хуҗасыз хайваннарны аулау һәм аларның санын җайга салу өлешендә «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Законының һәм «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының үтәлеше хакында | ноябрь | Т.Г. Һадиев |
| – «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2014 елның 29 декабрендәге Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында | декабрь | Т.Г. Һадиев |
| Башка мәсьәләләрне карау: | | |
| – федераль закон проектлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару инициативалары һәм мөрәҗәгатьләре турында | ел дәвамында | Т.Г. Һадиев |
| – чираттагы чорга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эш планы турында | квартал саен | Т.Г. Һадиев |
| – «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында | I квартал | Т.Г. Һадиев |
| – «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында | I квартал | Т.Г. Һадиев |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эше йомгаклары турында | декабрь | Т.Г. Һадиев |

| | | |
|---|---|---|
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эшенең якынча планы турында | декабрь | Т.Г. Һадиев |
| – «Татарстан Республикасында органик авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында | IV квартал | Т.Г. Һадиев |

**Социаль сәясәт комитеты**

| | | |
|---|---|---|
| 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | С.М. Захарова |
| Контроль мәсьәләләр: | | |
| – Татарстан Республикасында түләүсез паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру өлешендә законнарны гамәлгә ашыру турында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының һәм Казан шәһәре Балалар хосписы базасында сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында) | февраль | С.М. Захарова |
| – Татарстан Республикасында медицина реабилитациясе системасын үстерү турында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында) | март | С.М. Захарова |
| – Яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм аларны эшкә урнаштыру эшчәнлеген оештыру өлешендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәседәге законнарны гамәлгә ашыру турында | апрель | С.М. Захарова |
| – «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында | май | С.М. Захарова |



| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасында социаль ятимлекне кисәтү буенча профилактик, социаль-педагогик эш оештыру турында | июнь | С.М. Захарова |
| – Татарстан Республикасында массакүләм спортны үстерү турында | октябрь | С.М. Захарова |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының «Социаль өлкәдә дәүләти-хосусый партнерлык турындагы законнарны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 29 июнендәге 39 номерлы карарының үтәлеше хакында | ноябрь | С.М. Захарова |
| – «Социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидлар һәм гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законын мониторинглау йомгаклары хакында | декабрь | С.М. Захарова |
| Башка мәсьәләләрне карау: | | |
| – Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары мәгълүматын карау (социаль өлкә мәсьәләләре буенча) | ел дәвамында | С.М. Захарова |
| – чираттагы чорга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының эш планы турында | квартал саен | С.М. Захарова |
| – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм 2015 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турында доклад буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мәгълүматы хакында | апрель | С.М. Захарова |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты эше йомгаклары турында | декабрь | С.М. Захарова |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты эшенең якынча планы турында | декабрь | С.М. Захарова |

**Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты**

| | | |
|---|---|---|
| 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә Татарстан Республикасы законнары проектлары | ел дәвамында | Р.И. Вәлиев |
| Контроль мәсьәләләр: | | |
| – Татарстан Республикасында Әдәбият елы йомгаклары турында | февраль | Р.И. Вәлиев |
| – «Татарстан Республикасында укытыла торган дини дисциплиналар буенча уку-укыту һәм методик кулланмалар турында» түгәрәк өстәл тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру барышы турында (2013 елның 18 июне) | март | Р.И. Вәлиев |
| – Татарстан Республикасы мәктәпләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен куллану өлешендә «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәүнең барышы хакында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында) | апрель | Р.И. Вәлиев |
| – Россия киносы елы кысаларында республика чаралары турында | май | Р.И. Вәлиев |
| – Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясе проекты турында | июнь | Р.И. Вәлиев |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына караган мәсьәләләр буенча 2016 ел бюджетын гамәлгә ашыру барышы турында | октябрь | Р.И. Вәлиев |
| – «Талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы турында | ноябрь | Р.И. Вәлиев |
| – Авылда мәдәният оешмалары челтәрен үстерү (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында) | декабрь | Р.И. Вәлиев |
| Башка мәсьәләләрне карау: | | |
| – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының чираттагы чорга эш планы турында | квартал саен | Р.И. Вәлиев |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында | октябрь | Р.И. Вәлиев |
| – 2017 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында | октябрь | Р.И. Вәлиев |
| – 2016 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының эше турында | декабрь | Р.И. Вәлиев |
| – 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының якынча эш планы турында | декабрь | Р.И. Вәлиев |

## 7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссияләре утырышлары

**«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе**

| | | |
|---|---|---|
| – «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын, импорт алмаштыру мәсьәләләрен кертеп, үтәү турында | квартал саен | Т.Г. Һадиев |
| – «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын башкару хакында | квартал саен | Т.Г. Һадиев |
| – Авыл хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар квалификациясен күтәрү чаралары һәм аларны эшкә урнаштыру турында | I квартал | Т.Г. Һадиев |
| – 2030 елга кадәр Социаль-икътисадый үстерү стратегиясен импорт алмаштыру һәм авыл хуҗалыгы машиналарының үз производствосы өлешендә гамәлгә ашыру турында (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының берләштерелгән утырышында) | I квартал | Т.Г. Һадиев |
| – 2016 елда «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең эш йомгаклары турында | декабрь | Т.Г. Һадиев |
| – 2017 елга «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең якынча эш планы турында | декабрь | Т.Г. Һадиев |

**«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе**



| | | |
|---|---|---|
| – ТКХ өлкәсендә энергия нәтиҗәлелеге (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең Казан дәүләт энергетика университетындагы берләштерелгән утырышында) | март | Р.Т. Борһанов |
| – Республикада торак программаларын гамәлгә ашыру проблемалары һәм перспективалары (эконом класслы торак, аз катлы, арендалы торак, өлешле төзү һ.б.) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең берләштерелгән күчмә утырышында) | июнь | Р.Т. Борһанов |
| – Республикада гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программаларын гамәлгә ашыру йомгаклары һәм проблемалары (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең берләштерелгән күчмә утырышында) | сентябрь | Р.Т. Борһанов |
| – Күчемсез милекне дәүләт кадастр исәбенә алуны һәм күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны камилләштерү (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең берләштерелгән күчмә утырышында) | декабрь | Р.Т. Борһанов |

| | | |
|---|---|---|
| – 2016 елда «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең эш йомгаклары турында | декабрь | Р.Т. Борһанов |
| – 2017 елга «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең якынча эш планы турында | декабрь | Р.Т. Борһанов |
| **Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе** | | |
| – «Татарстан Республикасында түләүсез паллиатив медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру өлешендә законнарны гамәлгә ашыру турында» (Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының берләштерелгән күчмә утырышында) | февраль | С.М. Захарова |
| – «Татарстан Республикасында медицина реабилитациясе системасын үстерү турында» (Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының берләштерелгән утырышында) | март | С.М. Захарова |
| – «Ревматизм авыруларының медицина-социаль проблемалары» (Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең Казан шәһәренең 7 нче шәһәр клиник хастаханәсендәге күчмә утырышында) | апрель | С.М. Захарова |
| – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының берсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышы | октябрь | С.М. Захарова |



| | | | |
|---|---|---|---|
| | – 2016 елда Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе эше йомгаклары турында | декабрь | С.М. Захарова |
| | – 2017 елга Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе эшенең якынча планы турында | декабрь | С.М. Захарова |
| | **Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе** | кирәк булганда | Р.Ш. Рәхмәтуллин |
| | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе** | кирәк булганда | Р.А. Ратникова |
| | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе** | кирәк булганда | Ю.З. Камалтынов |
| 8. | **Татарстан Республикасы законнарын мониторинглау** | | |
| | – «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | А.Г. Хәбибуллин |
| | – «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы һәм «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары | ел дәвамында | Ш.Ш. Яһудин |
| | – «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Ш.Ш. Яһудин |

| | | |
|---|---|---|
| – Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2014 елның 28 маендагы 35-ТРЗ номерлы | ел дәвамында | Л.А. Якунин |
| – «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы күзәтүчесез хайваннарны аулау һәм аларның санын җайга салу өлешендә һәм «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Т.Г. Һадиев |
| – «Инвалидлар һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 14 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлешендә | ел дәвамында | С.М. Захарова |
| – «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Р.И. Вәлиев |
| – «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Р.И. Вәлиев |
| – «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Р.И. Вәлиев |
| – «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Р.И. Вәлиев |



| | | | |
|---|---|---|---|
| | – «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | ел дәвамында | Р.Т. Борһанов |
| | – «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | июль | Р.Т. Борһанов |
| **9.** | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары эшен оештыру чаралары** | ел дәвамында | Р.Т. Борһанов<br>Т.Г. Һадиев |
| **10.** | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Бердәм Россия» депутат фракциясе составындагы «Мәрхәмәт» берләшмәсе уздыра торган чаралар** | ел дәвамында | Т.П. Ларионова |
| **11.** | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәләре катнашында матбугат конференцияләре** | аерым план буенча | Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге |
| **12.** | **Парламентара хезмәттәшлек** («2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында» 2015 елның 23 декабрендәге 1006-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә) | ел дәвамында | Р.А. Ратникова<br>А.Г. Хәбибуллин |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округларындагы эше** | һәр айның беренче атнасы, Дәүләт Советы башка карар кабул итмәсә | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 14. | **Хисаплар, мәгълүматлар** | | |
| | – 2015 елның гыйнварыннан декабренә кадәр полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында хисабы | февраль | А.В. Хохорин |
| | – 2015 елда «Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлүе турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады | февраль | С.Х. Сабурская |
| | – 2015 елда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре турында доклад | март | Т.Д. Ногманов |
| | – 2015 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлүе турында доклад | март | Г.Л. Удачина |
| | – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап (Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 10 мартка кадәр тапшырыла) | Карау датасы, Татарстан Республикасы Президенты белән килештереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләре |



| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2015 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап | апрель | А.И. Демидов |
| | 20016 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының еллык доклады | декабрь | Э.Н. Фәттахов |
| 15. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында «Хөкүмәт сәгате» үткәрү, шул исәптән түбәндәге мәсьәләләр буенча:** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| | – Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалауда, аларның хокукларын яклауда балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләрнең эшчәнлеге турында | июнь | Ш.Ш. Яһудин |
| | – Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында | октябрь | Р.И. Вәлиев |
| | – Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында | ноябрь | А.Г. Хәбибуллин |
| | – 2016 елда коммуналь комплекс табигый монополияләрен һәм оешмаларын дәүләт җайга салуы турында | декабрь | Р.Т. Борһанов |
| | Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан импорт продукциясен алмаштыру бурычын үтәве турында | II ярты-еллык | Т.Г. Һадиев |
| 16. | **Түбәндәге мәсьәләләр буенча «түгәрәк өстәлләр» уздыру:** | | |
| | – Татарстан Республикасында дини белем бирү: хәзерге хәле һәм перспективалары | март | Р.И. Вәлиев |
| | – Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең сәнәгать мәйданчыкларын үстерү проблемалары һәм перспективалары | май | Р.Т. Борһанов |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – Милли сәясәт, телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру, милли иҗтимагый оешмалар белән үзара эшчәнлеге турында (Удмурт Республикасы Дәүләт Советының профильле комитеты катнашында) | май | Р.И. Вәлиев |
| | – Татарстан Республикасы икътисадына чит ил инвесторларын җәлеп итү өчен уңайлы шартлар тудыру турында | октябрь | Р.Т. Борһанов |
| | – җирле үзидарә өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру һәм алга таба камилләштерү турында | IV квартал | А.Г. Хәбибуллин |
| | – махсус икътисадый зоналарда салым ташламалары бирүнең нәтиҗәлелеге турында | IV квартал | Л.А. Якунин |
| 17. | **Бөтенроссия җирле үзидарә советының Татарстан региональ бүлекчәсе (ВСМС) эшен оештыру** | ел дәвамында | А.Г. Хәбибуллин |
| 18. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары утырышлары эшендә катнашулары** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 19. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары, федераль дәүләт органнары, Татарстан Республикасы ведомстволары коллегияләре утырышларында катнашуы** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 20. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатлары белән үзара эшчәнлеге** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 21. | **Дәүләт Советы каравына кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларына, шулай ук Дәүләт Советына керә торган федераль законнар проектларына юридик экспертиза уздыру; федератив мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм Татарстан Республикасында дәүләт төзелеше мәсьәләләре буенча бәяләмәләр әзерләү** | ел дәвамында | Хокук идарәсе |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. | **Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга тапшыру алдыннан аларга лингвистик экспертиза үткәрү** | ел дәвамында | Документлар белән тәэмин итү идарәсе |
| 23. | **Матбугат конференцияләре, радио һәм телевидениедә махсус тапшырулар уздыру, «Парламент хәбәрләре» мәгълүмати бюллетенен чыгару, республика массакүләм мәгълүмат чаралары өчен материаллар әзерләү** | ел дәвамында | Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге |
| 24. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү** | ел дәвамында | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге |
| 25. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы утырышын әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм итү** | ел дәвамында | С.М. Захарова |
| 26. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары катнашында төрле категорияләрдәге гражданнар өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Ачык ишекләр көннәре уздыру** | ел дәвамында | Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге |
| 27. | **Татарстан Республикасы югары уку йортлары белән хезмәттәшлек (югары уку йортлары студентларының Дәүләт Советына килүе, Дәүләт Советы депутатлары белән очрашулар, таныштыру һәм производство практикалары узу, шуларның нәтиҗәләре буенча мәгълүмат алу (анкеталар, эссе, тестлар)** | ел дәвамында | Оештыру идарәсе |
| 28. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында дәүләт граждан хезмәтен кадрлар белән тәэмин итүне камилләштерү, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау чараларын күрү** | ел дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 29. | **2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының коррупциягә каршы көрәш программалары чараларын үтәве** | ел дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруда гамәли ярдәм күрсәтү өчен муниципаль районнарга чыгуларда катнашуы** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 31. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе хезмәткәрләренең халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өчен муниципаль районнарга чыгуларда катнашулары** | ел дәвамында | А.А. Ощепков |
| 32. | **Дәүләт Советы депутатлары һәм аларның ярдәмчеләре өчен парламент семинарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре өчен уку семинарлары, тренинглар үткәрү** | ел дәвамында | Оештыру идарәсе |
| 33. | **«Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасын чыгару** | ел дәвамында | Документлар белән тәэмин итү идарәсе |
| 34. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми сайтын актуаль халәттә тоту** | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген мәгълүмати-технологик тәэмин итү бүлеге, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структур бүлекчәләре |
| 35. | **Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларына таныклыклар тапшыру** | ел дәвамында | Оештыру идарәсе |
| 36. | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары катнашында Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында «Граждан. Җәмгыять. Дәүләт» темасына парламент дәресе үткәрү** | февраль | Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге |
| 37. | **2016 елгы парламент дәресе кысаларында мәктәп укучылары арасында уздырылган республика иҗади конкурсына тантаналы йомгак ясау** | февраль | Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге |
| 38. | **Татарстан Республикасы Матбугат көненә багышланган ММЧ республика медиафорумын үткәрү** | май | Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге |
| 39. | **Яшь парламентарийлар мәктәбенә ярдәм күрсәтү** | Июль, ноябрь | С.М. Захарова |
| 40. | **Россия Федерациясенең яшь гражданнарына паспортлар тапшыру** | декабрь | Оештыру идарәсе |



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 69. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, хисап бирү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмматшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 4 феврале
№ 1041-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 4 февралендәге
1041-V ДС номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешен арттыру буенча күрелә торган чаралар турында.

2. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре хакында.

3. Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән, сәнәгатькә, кече һәм урта бизнеска ярдәм итү буенча закон чыгару инициативаларын әзерләү турында. Татарстан Республикасында сәнәгать (индустриаль) парклары турында Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү сроклары хакында.

4. Татарстан Республикасында үсеше алдан билгеләнә торган территорияне (Чаллы шәһәре) һәм «ИнноКАМ» проектын гамәли үстерү проблемалары һәм перспективалары турында.



5. «Worldskills – 2019» эшче һөнәрләр буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерлек һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең гамәлләр программасы хакында.

6. Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары җитештерә торган продукция белән импортны алмаштыру бурычларын гамәлгә ашыру барышы турында.

7. Татарстан Республикасында хуҗалык итүнең кече рәвешләренә ярдәм итү буенча өстәмә чаралар хакында.

8. Халыктан сатып алына торган сөткә бәяләрне арттыру турында.

9. Авыл җирендә яшәүчеләргә терлек асрау өчен ашлыкны, фуражны, печәнне, саламны бердәй бәядән сатуны оештыру хакында.

10. Башка регионнарның тәҗрибәсен кулланып, авыл хуҗалыгы производствосының инновацияле үсеше турында (сөт бирә торган мөгезле эре терлек азыгы белән тәэмин итеп, соңыннан сөтне җыеп, авыл җирендә яшәүчеләргә шушы терлекне бирү; фермерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә теләүче күпбалалы гаиләләр өчен, соңыннан продукцияне җыеп, хуҗалык, көнкүреш төзелмәләре (терлек өчен урыннар, теплицалар) булган торак йортлар төзү).

11. Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын дәүләт планлаштыруы, дәүләт заказы һәм авыл хуҗалыгы продукциясен гарантияләнгән бәягә гарантияле сату принципларында үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын әзерләү хакында.

12. Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елы кысаларында күрелә торган чаралар турында.

13. Займище торак массивы районында Идел елгасы тугаенда төзелешне туктатуга юнәлдерелгән табигатьне саклау чаралары хакында, шул исәптән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән үзара эшчәнлеге турында.

14. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында.

15. Татарстан Республикасында торак программаларын гамәлгә ашыру проблемалары һәм перспективалары турында (эконом класслы торак, аз катлы, арендалы торак төзү, өлешле төзү).

16. Гражданнарны яшәү өчен яраксыз, шул исәптән актив ишелү процесслары аркасында, дип танылган авария хәлендәге

муниципаль торак фондыннан һәм авария хәлендәге торак фондыннан күчерү мәсьәләләрен хәл итү перспективалары хакында.

17. Тузган һәм авария хәлендәге йортларда социаль наем шартнамәләре буенча яшәүче гражданнар өчен социаль торак төзүнең күләмнәре турында.

18. Йорттагы гомуми мөлкәтнең һәм җир кишәрлегенең бәясен исәпкә алып авария хәлендәге торакның квадрат метрына сатып алуның адекват бәясен билгеләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә ассигнованиеләр бүлеп бирү хакында.

19. Татарстан Республикасында рөхсәтсез төзүне булдырмауга юнәлдерелгән чаралар турында.

20. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен күрелә торган чаралар хакында.

21. 2015 елда ятим балаларны һәм ятим балалар арасыннан булган затларны торак урыннар белән тәэмин итү программасын гамәлгә ашыру һәм алдагы елларга перспективалар турында.

22. Гражданнарның торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының аларның керемнәренә нисбәтен туры китерүгә юнәлдерелгән чаралар хакында (гражданнарның торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнары минималь пенсия күләменең яртысын тәшкил итмәскә тиеш).

23. Бердәй исәп-хисап үзәкләре, шулай ук идарәче оешмалар рәвешендәге арадашчыларны бетереп, ТКХ өлкәсендә үзгәртеп төзү мөмкинлеге турында.

24. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның хокукларын коммуналь һәм торак хезмәт күрсәтүләренә тарифларны киметү юлы белән яклауга юнәлдерелгән чаралар хакында.

25. Татарстан Республикасында авыр тормыш хәлендә һәм куркыныч социаль хәлдә калган гаиләләргә социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыру турында.

26. Балалар өчен социаль приютларның торышы турында.

27. Татарстан Республикасында инвалидларны техник реабилитация чаралары һәм протез-ортопедия әйберләре белән тәэмин итү буенча 2014 – 2015 елларда күрелгән чаралар турында, шулай ук 2016 елга фаразлар хакында.

28. Ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның торак-коммуналь хезмәт күрсәтүчеләргә бурычларын юкка чыгару буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары башкара торган эш турында.

29. Опека һәм попечительлек органнарын кадрлар белән тәэмин итүнең республика һәм федераль законнарга туры килүе турында.



30. Казан шәһәрендә балаларга медицина ярдәме күрсәтүдән файдалана алу мөмкинлеген арттыру максатларында Казанда күппрофильле балалар хастаханәсе һәм балалар өчен йогышлы авырулар хастаханәсенең икенче чиратын төзү зарурлыгы турында.

31. Беренче медицина ярдәме күрсәтелә торган дәвалау учреждениеләрендә кабул итү – диагностика бүлекчәләрен реконструкцияләү яисә төзү буенча 2016 елга планнар турында.

32. Онколог табибларга чиратның зур булып калуына һәм гражданнарның химиотерапия алуны көтү чорының озак булуына бәйле рәвештә Чаллы шәһәрендә «Республика клиник онкология диспансеры» ДАССУ филиалы өчен бина төзү перспективалары турында.

33. Орфан (сирәк) авырулар белән авыручы гражданнарны дарулар белән тәэмин итү проблемаларын хәл итү буенча өстәмә чаралар турында. Хәзерге вакытта әлеге юнәлешне финанслауга ихтыяҗ Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар күләменә караганда берничә тапкыр зуррак.

34. Түләүсез медицина кысаларында күрсәтелә торган хезмәтләргә чират булдыру исәбенә түләүле хезмәтләрне арттыру турында.

35. Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан ашыгыч медицина ярдәмен финанслауга чыгымнарның 2010 – 2015 елларда артуына карамастан, күрсәтелә торган медицина хезмәтләренең түбән сыйфатлы булуы (кирәкле даруларның булмавы, медицина персоналының авыруларны ашыгыч ярдәм машинасына кадәр китереп куюдан баш тартуы, алдан куелган диагнозларның дөрес булмавы) турында.

36. Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәмен үстерү перспективалары турында, шул исәптән бу мәсьәләне хәл итәр өчен ведомствоара үзара эшчәнлекне оештыру өлешендә.

37. Яшь ярымнан өч яшькә кадәр булган балаларны мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә урыннар белән тәэмин итү турында. Баланы балалар бакчасында урын белән тәэмин итү мөмкинлеге булмауга бәйле рәвештә акчалата компенсация бирү мөмкинлеге (Россия Федерациясенең башка субъектлары мисалында) турында.

38. Татарстан Республикасында баланы мәктәпкәчә мәгариф учреждениесенә йөртү бәясен киметүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

39. Казан шәһәрендә мәдәният учреждениеләрен (Ленин исемендәге мәдәният йорты, Сәетгалиев исемендәге мәдәният йорты, «Сәйдәш» мәдәният үзәге, «Московский» мәдәният һәм спорт үзәге) реконструкцияләү яисә капиталь ремонтлау перспективалары турында.

40. Бюджет тармагы хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру чараларын тормышка ашыру (тармаклар буенча) турында.

41. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе өчен яңа бина төзү перспективалары турында.

42. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын төзү һәм капиталь ремонтлау планнары турында.

43. Уку-укыту процессын бер сменалы оештыру максатында Татарстан Республикасы шәһәрләрендәге яңа микрорайоннарда яңа гомуми белем бирү оешмалары төзү перспективалары турында.

44. Милли мәгариф системасын үстерү турында.

45. Укытучыларны яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү турында.

46. «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында.

47. Татарстан Республикасы территориясендә криминаль вәзгыятьне мониторинглауны оештыру һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законында каралган мәсьәләләр буенча фәнни-тикшеренү эшчәнлеген үстерү чаралары турында.

48. «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү чаралары турында.

49. Татарстан Республикасында халыкның төрле категорияләренә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында.

50. Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында.

51. Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар арасындагы хокук бозуларны киметү чаралары турында.

52. Муниципаль берәмлекләр чикләрен һәм Татарстан Республикасы чикләрен кадастр исәбенә кую мәсьәләсен хәл итү турында.

53. Җирле үзидарә органнарында эшләүче хокук белгечләренең квалификацияләрен күтәрү эшен оештыру турында.



54. Муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә финанс белән тәэмин ителеше һәм аларны җитәрлек финанслар белән тәэмин итү перспективалары турында.

55. Дәүләт гаилә сәясәтен гамәлгә ашыру эшен координацияләүгә җаваплы башкарма хакимият органын билгеләү турында.

56. Татарстан Республикасында спорт корылмаларыннан нәтиҗәле һәм рациональ файдалану турында.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 70. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты каршындагы Эксперт советы составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2015 елның 13 мартындагы 462-V ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты каршындагы Эксперт советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Эксперт советы составыннан И.М. Шабаевны чыгарырга;

б) Эксперт советы составына түбәндәгене кертергә:

Шәрипов Ронис Нәкыйп улы – «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» ААҖ генераль директоры (килешү буенча).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 4 феврале
№ 1042-V ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 71. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советы составы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советы составын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 4 феврале
№ 1043-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 4 февралендәге
1043-V ДС номерлы карарына
кушымта

### Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советы составы

| | |
|---|---|
| Таһиров Индус Ризак улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы, Эксперт советы рәисе (килешү буенча) |
| Лотфуллин Марат Вазыйх улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, Эксперт советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Александровская Ирина Алексеевна | «Казан шәһәре Рус милли-мәдәни берләшмәсе» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе, Казан шәһәре Совет районының «93 нче гимназия» МБМУ директоры (килешү буенча) |
| Вәлиев Рафаэль Миргасыйм улы | Казан дәүләт мәдәният институтының фәнни эш буенча проректоры, профессор (килешү буенча) |
| Владимиров Николай Михайлович | Татарстан халыклары ассамблеясе Советы Рәисе урынбасары, Татарстан халыклары ассамблеясе Советы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |



| | |
|---|---|
| Галимуллин Фоат Галимулла улы | Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегенең татар әдәбияты кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы (килешү буенча) |
| Гыйбатдинов Марат Мингали улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге бүлек мөдире, педагогика фәннәре кандидаты (килешү буенча) |
| Ибраһимов Илфак Мирза улы | «Казан утлары» журналының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Исхаков Дамир Мәүләви улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының этнологик тикшеренүләр бүлеге баш фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы (килешү буенча) |
| Латышев Александр Николаевич | «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Мостафина Фәйрүзә Зөфәр кызы | «Чаллы дәүләт педагогика университеты» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры, педагогика фәннәре кандидаты (килешү буенча) |
| Нуриәхмәтов Галишан Закирҗан улы | Бөтентатар иҗтимагый үзәге рәисе (килешү буенча) |
| Пономарев Кирилл Николаевич | «Социаль һәм гуманитар белемнәр институты» хосусый югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең башкарма директоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Прохоров Юрий Петрович | Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фәне хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Сафиуллин Фәндәс Шакир улы | җәмәгать эшлеклесе, публицист (килешү буенча) |
| Сираева Наилә Мөҗәһит кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш консультанты, Эксперт советының җаваплы секретаре |

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 72. Ф.С. Гыймалтдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясе филиалы «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе директоры Гыймалтдинов Фирдус Салих улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 гыйнвары
№ 1-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 73. А.В. Кузнецовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Интерфакс-Поволжье» мәгълүмат агентлыгының бюро директоры Александр Владимирович Кузнецовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 гыйнвары
№ 2-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 74. В.И. Шакировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасында җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җирле үзидарә өлкәсендә норматив хокукый эш һәм муниципаль регистрны алып бару бүлеге башлыгы урынбасары Шакиров Владимир Илгизәр улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 3-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 75. Р.Э. Вафинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Балтач муниципаль районының җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Вафина Рәфилә Эдуарт кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 4-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 76. Р.М. Мөхәммәтшинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татар мәдәниятен үстерүгә һәм аны саклауга зур өлеш керткән өчен Киров өлкәсе татарларының региональ мәдәни-агарту иҗтимагый оешмасының идарә рәисе урынбасары, «ЭтноМир» милли мәдәниятләр үзәге муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең милли һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире Мөхәммәтшина Рәйсә Миңнебай кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 5-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 77. Л.А. Кудряшованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы ярдәмчесе Кудряшова Людмила Анатольевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 6-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 78. Д.Н. Степановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе оператив хезмәтенең 2 нче бүлеге оперуполномоченные Степанов Денис Николаевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 7-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 79. Г.М. Петровичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе оператив хезмәтенең «А» бүлеге өлкән оперуполномоченные Петрович Гүзәл Мирославовнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 8-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 80. А.А. Сухановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең бүлек башлыгы урынбасары Александр Александрович Сухановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 9-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 81. Е.М. Яковенконы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлекчәсе башлыгы Яковенко Елена Михайловнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 12 гыйнвары
№ 10-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 82. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен ВГТРК генераль директоры урынбасары, ВГТРК Региональ департаменты җитәкчесе Сабитов Рифат Абдулваһап улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 13 гыйнвары
№ 12-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 83. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (юридик зат булган сайлау комиссияләре әгъзаларының вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү бурычын билгеләү, шулай ук депутатларга кандидатларга караган счетлар, кертемнәр һәм кыйммәтле кәгазьләр хакындагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү тәртибен билгеләү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп,

депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2016 елның 11 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 13 гыйнвары
№ 14-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 84. В.А. Арсеньевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Чистай шәһәр суды судьясы Арсеньев Валерий Анатольевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 гыйнвары
№ 17-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 85. И.Т. Мусинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Югары Ослан үзәк больницасы» ДАССУ баш табибы Мусин Ирек Тәүфыйк улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 18 гыйнвары
№ 20-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 86. Т.А. Емелинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен сәламәтлек саклау тармагы ветераны, ТАССРның атказанган табибы, Бөек Ватан сугышында катнашучы Емелина Татьяна Андреевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 20 гыйнвары
№ 25-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 87. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Т. Борһанов, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 2[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 193-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Россия Федерациясе дәүләт стандартларына сылтамаларны төшереп калдыру хакында) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 2[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 193-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын 2016 елның 22 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 26 гыйнвары
№ 31-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 88. Л.Ш. Шаһвәлиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсенең социаль өлкәдә федераль бюджет чараларын финанс тикшерүе, бюджетара трансфертлар һәм бюджетара фондлар чаралары бүлегенең өлкән контролер-ревизоры Шаһвәлиева Ләйсән Шамил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 27 гыйнвары
№ 32-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 89. С.М. Маклаковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Аксубай муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Аксубай муниципаль районы «Аксу Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Нива» бүлекчәсе җитәкчесе Маклаков Сергей Михайловичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 гыйнвары
№ 33-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 90. В.Д. Сапеевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Аксубай муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Аксубай муниципаль районының «Сапеев Валерий Дмитриевич» крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы Сапеев Валерий Дмитриевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 гыйнвары
№ 34-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 91. Ә.Г. Сунеевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Аксубай муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Аксубай муниципаль районының «Аксубай» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары Сунеев Әхнәф Галимулла улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 гыйнвары
№ 35-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 92. И.З. Шәймәрдановны бүләкләү турында

Кеше һәм гражданн хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе Шәймәрданов Илнур Зөфәр улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 гыйнвары
№ 36-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 93. Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Е.К. Завойский исемендәге Казан физика-техника институты коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Е.К. Завойский исемендәге Казан физика-техника институты коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 гыйнвары
№ 38-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 94. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 194-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары квалификациясенең исемнәрен һәм кодларын төгәлләштерү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 194-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2016 елның 28 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 1 феврале
№ 39-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 95. Х.Г. Зәбировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Биектау муниципаль районында җирле үзидарәне үстерүгә зур өлеш керткән өчен Биектау муниципаль районының Олы Кавал авыл җирлеге башлыгы Зәбиров Хәлим Габделхак улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 феврале
№ 40-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 96. Р.Ә. Гарәфиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Биектау муниципаль районында җирле үзидарәне үстерүгә зур өлеш керткән өчен Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге башлыгы Гарәфиев Ренат Әнвәр улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 феврале
№ 41-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 97. Л.А. Клюеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Зеленодольск муниципаль районында җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының оештыру-кадрлар эше бүлеге башлыгы Клюева Людмила Александровнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 феврале
№ 42-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 98. Н.М. Тухтаркинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Зеленодольск муниципаль районында җирле үзидарәне үстерүгә зур өлеш керткән өчен Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы Николай Михайлович Тухтаркинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 феврале
№ 43-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 99. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 198-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (законнар үтәлешенә күзәтчелекне һәм аны тикшереп торуны гамәлгә ашыруга кагыла торган нигезләмәләрне төгәлләштерү буенча) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 198-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын 2016 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 феврале
№ 45-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 100. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 197-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»

197-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2016 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 феврале
№ 46-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 101. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 196-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрнең резидентлары — оешмалары мөлкәтен салым салудан азат итү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

